**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ГЛАВА ЧЕРЕМШАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
Улица М.Титова, дом 7, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЧИРМЕШӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**
М.Титов урамы, 7 йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс 8(84396) 2-52-30, email: Cmn.Cmn2@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

30 гыйнвар 2026 ел №16

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 20 февралендәге №160 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Чирмешән авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 20 февралендәге 160 номерлы карарына (Советның 05.06.2019 ел, №169, 30.09.2021 ел, № 37, 27.08.2024 ел, №119, 26.12.2024 ел, №137, 14.03.2025 ел, №141 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә «4) 2025-2027 еллар чорына 1,2 процент түбәндәгеләргә карата: гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы урыннар:

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән;

агымдагы салым чорына Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектлары;

2,5 процент түбәндәгеләргә карата:

проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектлары».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Р.Т. Айбатов